# Алар даны мәңгелек

***(Бөек Җиңүнең ... еллыгына)***

А л ы п б а р у ч ы . Хәерле көн, сугыш һәм хезмәт ветераннары! Сезнең барыгызны да бөек тантана, зур шатлык — Бөек Җиңүнең ... еллык бәйрәме белән котлыйбыз!

Илебез күгенең ... ел буена аяз булуы белән без сезгә бурычлы. Озын гомер, тыныч көннәр насыйп булсын барыбызга да!

Матурлыгы өчен бу көннәрнең
Кемнәр генә корбан булмаган!
Исемнәрен тарих безгә үзе
Саклап килә ерак еллардан!
Туган ил хакына,
Туган җир хакына
Авылдашлар башын салдылар.
Безнең гомер өчен алар
Мәңгегә чит илдә калдылар!

*Кичәне ачу өчен сүз Ветераннар советы рәисенә бирелә.*

А л ы п б а р у ч ы . Хөрмәтле кунаклар! Бу Җиңү зур корбаннар аша килде һәм менә ... ел инде илебез халкы тыныч тормышта яши. 4 ел сугыш дәвамында халкыбыз тудырган зур батырлыклар һәм кичергән зур газаплар ... ел буена да, 100 ел буена да онытылырлык түгел. Каһарманнар даны мәңгелек.

Күп илләрне кара күмер ясап,
Үлек белән түшәп юлларны,
Канга туймас Гитлер безгә табан
Суза хәзер шакшы кулларын.
Җиребезне безнең кол итмәкче,
Кол итәргә азат халыкны
Хыяллана фашист, этләреннән
Талатырга бездән байлыкны.
Көлеп аккан көмеш чишмәбездә
Канга баткан кулын юмакчы.
Кырым кояшында кызынмакчы,
Балабызны килеп бумакчы.
Юк бу илдә урын юлбасарга,
Үз башына төшәр хәсрәте.
Туплар булып ява явызларга
Халкыбызның ачы нәфрәте.
Тыныч иде әле таңнарыбыз,
Аяз иде әле иртәләр.
Дошман басып керде илебезгә,
Ир-егетләр яуга китәләр.

22 июнь. Таң атып килә. Гүзәл авыллар, шәһәрләр тыныч йокыда. Әниләренең җылы куенында тәмле төшләр күреп нәни сабыйлар изрәп йоклыйлар. Шул вакытта канга туймас фашист этләре безнең чикне бозып авылларны, шәһәрләрне үлем утына тоттылар. Бөек Ватан сугышы башланды.

*(Фонограмма: Левитан тавышы. Сугыш башлануы хәбәр ителә.)*

Берни белми изрәп йоклаган сабыйлар зәңгәр күккә карап хәрәкәтсез калдылар. Зәңгәр күкне канлы корым каплады.

Аяусыз сугыш башланды.

Бөек Ватан сугышына безнең авылдан ... кеше китте.

*(Солдатлар турында җыр.)*

Бер кайтырбыз диеп киткән юлдан
Китсәләр дә, алар кайтмады.
Алар өчен бары җилләр генә
Ачып-ябып йөри капканы.

Бер кайтмасак, бер кайтырбыз дип китсәләр дә, күпме авылдашларыбыз туган туфрагын күрү бәхетенә ирешә алмады. Алар еракта мәңгелек йокыга талдылар. Туган җирләре өчен башларын салган бу батырларны онытырга безнең хакыбыз юк. Алар безнең белән, безнең арада.

Иле исән калган батыр улың

Яши халкы белән ул бергә.
Тыныч тормыш өчен тырыша ул,
Җырлап иген игә ул җирдә.
Хөрмәтле кунаклар, ветераннар!
Безнең якты киләчәгебез, сабыйларның тыныч йокысы өчен башларын салган авылдашларыбызны зур хөрмәт белән искә алыйк. Иптәшләр! Бер минутка тынлык.
*(Зал басып тын кала.)*
Туган җирләрдән еракта башларын салган авылдашларыбызның якты истәлеге күңелләрдә мәңге сакланыр. Авылыбыз уртасында алар хөрмәтенә салынган һәйкәл — моның ачык мисалы. Узган сугыштан безнең авылыбызга барлыгы ... кеше әйләнеп кайтты.
*Ут сүнә, берничә минуттан соң яна. Сәхнәдә кулына кылыч тоткан солдат һәйкәле. Таякка таянган, кулына чәчәкләр тоткан карчык боек кына һәйкәл янына килә.*
Ана *(карчык).* Исәнме, улым, менә мин яңадан синең яныңда. Салкын түгелме, балакаем?
Улы *(һәйкәл).* Юк, әнкәем, салкынның ни икәнен мин белмим. Миңа беркайда да салкын булганы юк.
А н а . Нигә үзеңне сакламадың, улым? Хәтерлисеңме: «Әнкәем, Берлинны гына алыйк та, алтыбыз алты яктан кайтып керербез, — дигән идең. — Әнкәй, син беребездән беребезгә кунакка гына йөрерсең, йөзгә кадәр яшәрбез», — дип язган идең?
У л ы. Әйткән сүзләрем һәрвакыт йөрәк түрендә, әнкәем. Әмма башкача мөмкин булмады... Дошман белән көрәш аяусыз булды. Мин генәме соң? Меңнәр, миллионнар илебез өчен үз-үзләрен аямыйча көрәштә башларын салды. Кайберәүләрнең сугыштан киткән балаларының берсе дә кайтмады. Ә синең *(Фәлән-фәләнең)* кайтты әле.
А н а . Калганнарыгыз да янымда булса, куанычымның чиге булмас иде. Сугышка киткәндәге сыман бер-бер артлы кайтып керерсез дә уен-көлке белән өебезне ямьләрсез кебек.
У л ы. Картлык көнеңдә ничек яшисең соң, әнкәй?
А н а . Барысы да җитеш, улым. Шәһәрдән шәһәргә, авылдан авылга кунакка гына йөрим. Оныкларым санап бетерерлек түгел.
У л ы. Сине яраталармы соң алар, әнкәй?
А н а . Яраталар, бик тә яраталар. Берсеннән дә авыр сүз ишеткәнем юк, әби дип үлеп торалар. Бәлки, мине тиз генә танымагансыңдыр да, балам?
У л ы. Таныдым, әллә кайлардан таныдым, әнкәем, күз нурым. Әгәр мөмкин булса, мин сине кочагыма алыр идем. Әмма минем кулларым, инде үзем дә — кузлы тимердән. Димәк, мәңгелек, әнкәем.
А н а . Йөрәк түремдә 9 ай буе йөрткән, күкрәк сөтемне имезеп үстергән баланы югалтуы ай-һай авыр шул, улым.
У л ы . Шулайдыр, әнкәй! Ләкин син сөен! Без бит Ватан өчен, бүгенге шушы тыныч көннәр өчен һәлак булдык. Тез чүгеп, кол булып яшәсәң, бу дөньяның ни рәхәте булыр иде?
А н а . Шулай, улым, дөрес әйтәсең! *(Ана чәчәкләрне куя.)*
А л ы п б а р у ч ы .
Узган авыр юлларыңны Яраларың да төзәлсен,
Онытырга тырыш, ана. Инде тынычлансана.
Сугыштан барлыгы ... кеше әйләнеп кайтты. Ләкин ел- дан-ел ветераннарыбыз сафы да сирәгәя бара. Җиңүнең ... еллыгын бәйрәм иткәндә арабыздан киткән ветераннарны онытмыйк. Әйе бик зур афәтләр, олы хәсрәтләр алып килде бу сугыш илебез халкына. «Исән-сау әйләнеп кайтыгыз, җиңү белән кайтыгыз, онытмагыз!» — дип озаткан иде авыл халкы үзенең кадерле улларын. Аналарның, йөзләренә яулык каплап, тавышсыз гына елаулары, күпләрнең тамагына кереп утырган хәсрәт төере озату тантанасында артык сизелмәде. Чөнки алар улларының әйләнеп кайтырына ышанганнар иде әле.
Үгет-нәсыйхәтләрнең,әманәт-нәзерләрнең, ачы күз яшьләренең шаһиты булды олы юл.
Авыр, бик авыр еллар иде. Ләкин түзделәр, иреннәреннән кан саркыганчы түзделәр. Дошманны тизрәк туган җиребездән куып чыгару. Менә шушы олы максатка ирешүдә ... авылы халкы да йөрәкләреннән өзеп улларын, кызларын бирде. Авыл язмышы ил язмышына кушылды. Һәр көнне үзәк өзгеч хәбәрләрдән торган ул көннәрнең шаһиты, Ватан сугышы елларында тракторда эшләгән *(Фәлән)* апага сүз бирәбез. Тылда күргән авырлыкларыгыз турында сөйләсәгез иде. *(Апа сөйли.)*
А л ы п б а р у ч ы . Әйе, ирләре, уллары, туганнары зур батырлыклар күрсәткәндә, тылдагы хатын-кызларыбыз үзләрен аямыйча эшләделәр. Тылдагы хатын-кызларның батырлыгы сугыш кырында туган батырлыкка тиң.

Сүзне *(Фәлән)* апага бирәбез. *(Апа сөйли.)*
Сезнең өчен «Ак күлмәкле каеннар» дигән җыр юллыйбыз. *(Җыр башкарыла.)*
Алып баручы. Авылдашларның сугыш кырындагы хәбәрләрен хатлар аша белеп тордык.
Ай, ул кош теледәй солдат хатлары! Күпме кеше тилмереп көтте аларны. Һәр гаиләгә килгән кайгыны да, шатлыкны да бергә кичерә иде авыл халкы. Хәсрәт белән янәшә йөргән шатлык та килә иде кешеләргә. Шушы ике нәрсә йөрәкләрне телгәли иде. Кара пичәтле кош теледәй шушы кәгазь кисәге бәгырьләрне өзеп күпме авылдашлардан кан-яшь түктерде. *(Хатлар укыла.)*

Хәзер сүзне сугышта катнашкан ветеранга бирәбез.
*(Ветеран сөйли.)*
*Концерт номеры. «Диңгезче» биюе.*
Алып баручы. Совет халкы, 4 елдан артык кан коеп, үз иминлеген генә саклап калмады, фашизм изүе астында газаплanучы тугандаш халыкларга да азатлык алып бирде.
Яшәү өчен, авылдашларыбызның бәхетле киләчәге өчен күпме авылдашларыбызның гомере киселде. Ниһаять, зур корбаннар биреп алынган Җиңү көне килде.
1945 ел. 9 май. *(Җиңү көе ишетелә.)*
Менә ... ел инде тыныч хезмәт фронтында эш кайный. Ләкин сугыш китергән тирән хәсрәт, яралар һаман да үзен сиздерә. Ветераннарның күкрәгендә кыймылдаган мина кыйпыл- чыгы аша, әти сүзен әйтергә тилмереп үскән сабыйлар аша, ничә еллар буена олы юлдан күзен алмый газиз балаларын көткән аналар аша, әле һаман бер-берсен эзләүче фронтовик- дуслар аша...
Хөрмәтле сугыш ветераннары!
Сезне бәйрәмегез белән чын күңелдән котлыйбыз.
Сугыш ялкыны безнең дөньяны
Чолгап алмасын яңадан.
Сакла, сакла тынычлыкны,
Дан тынычлыкка, дан, дан, дан!

# Сезнең тормыш үзе батырлык

Сәхнә чәчәкләр һәм тасмалар белән бизәлгән. Сәхнә түренә «Сезнең тормыш — үзе батырлык» дип язылган. Сәхнәнең бер почмагына «Хезмәттәге батырлык өчен» медаленең макеты эшләнгән. Кунаклар өчен өстәлләр, урындыклар куелган, өстәлләрдә чәчәкләр.
Сәхнә ябык. Лирик көй ишетелә. Сәхнә ачыла. Көй акрыная. Ике алып баручы чыга.
Беренче алып баручы. Исәнмесез, кунаклар, тыл батырлары!
Икенче алып баручы. Исәнмесез, авыл уңганнары! Исәнмесез, апалар-абыйлар, әтиләр-әниләр, әбиләр һәм бабайлар!
Беренче алып баручы. Бүген без, сезнең батырлыкларга яңадан бер кабат сокланыр өчен, сезгә дан һәм мәдхия җырлар өчен һәм сезнең түземлегегез, сабырлыгыгыз алдында баш ияр өчен бу залга җыелдык.
Икенче алып баручы. Безнең бүгенге бәйрәмдә район җитәкчеләре катнаша. Сүзне *(Фәлән)*гә бирәбез. *(Чыгыш.)*
Беренче алып баручы. Хөрмәтле ветераннар, *(Фәлән)* башкаруында халкыбызның Нәкый Исәнбәт сүзләренә иҗат ителгән «Илкаем» җыры сезгә музыкаль сәламебез булып яңгырасын. *(Җыр.)*
Икенче алып баручы. Сезнең язмыш сугыш уты белән бергә үрелгән.
*(«Изге сугыш» («Священная оойна» ) көе ишетелә.*
*Көй яңгыравы астында шигырь укыла.)*
Ул елларны ничек онытасың, —
Ил язмышы кылыч йөзендә.
Ир-егетләр китте яу кырына,
Алып көче тоеп үзендә.
Ирләр китте, кызлар елап калды,
Шаулап калды иген, өлгереп.
Басу капкасына чаклы озата барды
Яше, карты, барысы өзелеп.
Ирләр китте, кызлар елап калды,

Елап калды күпме хатыннар.
Туйда кигән күлмәкләре калды,
Күпме бала калды, ятимнәр.
*(Музыка бетә.)*

Б е р е н ч е   а л ы п   б а р у ч ы . Әйе, авылда картлар, хатын-кызлар һәм балалар гына калды. Ә тормышны алып барырга кирәк иде — игенен дә игәргә, балаларны да ач-ялан- гач итмәскә, сугышка төрле җылы киемнәр дә әзерләп җибәрергә, гомер буе бетмәс төсле тоелган налогын да илтеп түләргә кирәк иде. Ләкин сез сынмадыгыз, сыгылмадыгыз.

Хәзер шул чорда сезнең яратып җырлана торган җырла- рыгызның берсен — «Уракчы кыз» җырын ишетерсез. Нәкый Исәнбәт сүзләре, халык көе. Аны ... авылының сугыш һәм хезмәт ветераны *(Фәлән)* ага *(Фәләнов)* башкара. *(Җыр.)*

Хәзер шул еллар турында әйтеп китү өчен сүзне ... авылы ветераннары исеменнән пенсионер-укытучы *(Фәлән)* апага бирәбез. *(Фәлән) апа сөйли.)*

И к е н ч е   а л ы п   б а р у ч ы . Күпләрегез, корыч айгырны иярләп, тракторларга утырдыгыз. Ул тракторлар еш ватыла, әле бер урыны туктап кала, әле башкасы коелып төшә. Ә сабан артында — әле яңа гына сабыйлыктан чыгып килә торган япь-яшь кызлар. Ә хәзер ... авылы ветераннары исеменнән, сугыш вакытында механизатор булып эшләгән *(Фәлән)* апага сүз бирәбез. *(Фәлән) апа сөйли.)*

Б е р е н ч е   а л ы п   б а р у ч ы . Хөрмәтле механизатор булып эшләгән хатын-кызлар! Сезнең сөеклеләрегез, әтиләрегез, абыйларыгыз танкларга каршы атакага күтәрелсә, машиналар белән азык-төлек, корал ташыса, сез тимер айгырларыгыз белән җир сөрдегез, чәчтегез, сукаладыгыз. Һәм тылда икмәк җитештереп, сугышка озатыштыгыз. Сез бу батырлыгыгыз белән Җиңү көнен якынайттыгыз. Рәхмәт сезгә!

И к е н ч е   а л ы п   б а р у ч ы . Сезнең өчен *(Фәлән)* җырлый. *(Җыр яңгырый.)*

Б е р е н ч е   а л ы п   б а р у ч ы .
Чабатадан, тездән суга батып,
Язгы чәчү җитәр алдыннан
Чыгып киткән икән симәнәгә
Хатын-кызлар безнең авылдан.
Сыерлары юлда ятып калган,
Җилкәләргә күчкән симәнә.
Бу турыда бүген сөйләгәндә
Әнкәй һаман елап җибәрә.
Кырык, илле чакрым язгы суда —
Кайталмасаң, илең ач кала.
Хатыннарда тик бер генә хәсрәт —
Һәр йорт саен көтә ач бала.
Әтиләрнең сугышып йөргән чагы,
Безнең яңа туган ел булган.
Капчык аскан егермеләп хатын
Басуларга кайтып егылган.
Орлык кайткан безгә гомер булып,
Без ни бирдек икән кайтарып?
...Әниләрнең әле яшәр чагы,
Китәләр шул иртә картаеп.
Бер шырпысыз түзгән, керосинсыз,
Чәй-шикәрсез түзгән авыл ул.
Сыер боты кадәр малайлары
Ил туйдыра — шундый авыл ул.
Тәпи йөрер-йөрмәс бала-чага,
Буразнадан билчән утаган.
Илгә — икмәк, авыл үзе өчен
Көлчә салган алабутадан.
Бер бәләкәй көлтә ега алган
Ул чорларның нужа хуҗасын.
Олылар күк күтәргән бит шулар
Ил хәсрәтен, Ватан нужасын.

И к е н ч е а л ы п б а р у ч ы . Ә хәзер сезнең каршыгызга *(Фәлән)* әбине чакырабыз. *(Чыгыш.)*
Б е р е н ч е а л ы п б а р у ч ы . Балачагын, яшьлекләрен сугыш урлаган, шулай да эштән арып кайткан килеш, ач-ялан- гач килеш, су буйларында, кичке уеннарда, аулак өйләрдә күңел ачарга үзләрендә көч-дәрт тапкан сугыш чоры яшьләре өчен *(Фәлән)* җырлый. «Өйләнеп кайтыгыз». Р. Хәсәнов көе, М. Шиһапов сүзләре. *(Җыр.)*
И к е н ч е а л ы п б а р у ч ы . Хөрмәтле тыл фидакарьләре! Авылда нинди эш булса, шуларның барысы да сезнең кулдан үткән. Ил язмышы да сезнең язмышыгыз иде. Шул чорларны искә алу өчен сүзне ... авылы ветераннары исеменнән ... булып эшләгән *(Фәлән)*гә бирәбез. *(Чыгыш.)*
Б е р е н ч е а л ы п б а р у ч ы . Бөтен булган физик авырлыкларга түзәр идең әле, авылларга кара пичәтле кәгазьләр агыла. Алма кебек хатыннар балаларын кочаклап ирсез, сабыйлар — әтисез, җиләк кебек кызлар ярсыз калалар. Ләкин, хөрмәтле хезмәт ветераннары, сез сынып та, сыгылып та төшмәдегез. Тизрәк Җиңү килсен дигән теләк сезне тагын да тырышыбрак эшләргә өндәде. Бик зур рәхмәт сезгә!
*(Концерт номеры.)*
И к е н ч е а л ы п б а р у ч ы . Сүзне ... ветераннары исеменнән пенсионер *(Фәлән)* апага бирәбез. *(Чыгыш.)*
Б е р е н ч е а л ы п б а р у ч ы . Сугыш я т и м иткән яшьләр, исән калган әтиләр кайтканда, сезнең йөрәкләр сыкрады, күзләргә яшь килде, башкаларның әтиләрен күргәндә: «Их, минем дә әтием исән булса иде», — дип авыр суладыгыз, башкалар «минем әти» дип сөйләгәндә сезнең «әти» дип авыз тутырып әйтер көнегезне каһәр суккан сугыш мәңгелеккә алып калган иде. Үз тырышлыклары белән сугыш бетүен якынайткан үсмерләр гомергә ятим булып калдылар.
Сезнең өчен *(Фәлән)* А. Имаеваның Р. Миңнуллин сүзләренә язылган «Әткәм моңы» җырын башкара.
И к е н ч е а л ы п б а р у ч ы . Сугыш беткәч тә, сез, тыл каһарманнары төнне көнгә, көнне төнгә ялгап эшләвегезне дәвам иттегез. Чөнки сугышка киткән ир-атларның яртысыннан күбесе һәлак булган, ә илдәге сугыш китергән хәрабәләрне торгызырга кирәк иде. Сез тагын ил язмышына кушылып, хезмәткә җигелдегез. Сезнең арада әле хәзерге көнгә кадәр намус белән үз хезмәтләрен башкаручылар байтак. Күпләрегез гаиләдә олы ихтирамлы кешеләр, балаларыгызның таянычы, оныкларыгызның юанычы. Сез әле дә олы йөрәкле, нык бәдәнле, саф күңелле әүлия затлар, сугыш чоры кешеләре. Тагын бер кат рәхмәт сезгә.
Халкыбызның «Сибел^ чәчем» җырын *(Фәлән)* башкара. *(Җыр.)*
Б е р е н ч е а л ы п б а р у ч ы .
Картаймагыз әле, ветераннар,
Картаймагыз, әй, тынгысыз җаннар!
Сезгә тиеш әле бик күп язлар,
Сезгә тиеш әле бик күп назлар.